ГРАЖДАННАР ҖЫЕНЫ КАРАРЫ

Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының Яңа Арыш авыл җирлеге составына керүче Яңа Арыш авылы торак пунктында

2024 елның 25 ноябре № 1

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә, Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының Яңа Арыш авыл җирлеге составына керүче Яңа Арыш авылы торак пунктында гражданнар җыены Карар кылды:

1.2025 елда Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Яңа Арыш авыл җирлегенең Яңа Арыш авылла торак пунктлары территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән балигъ булган һәр кешедән, көндезге формада белем алучы студентлардан, өлешчә мобилизациягә бәйле рәвештә хәрби хезмәткә чакырылган һәм контракт буенча СВО зонасында хезмәт иткән мобилизацияләнгән гражданнар , 300 сум күләмендә үзара салым кертергә.

2. Алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтергә::

- торак пункт чикләрендә гомуми файдаланудагы җирле әһәмиятле автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту;
- торак пункт территориясен төзекләндерү;
-су белән тәэмин итү һәм ташу системаларын, су җыю манараларын, скважиналарны һәм су белән тәэмин итү чыганакларыннан су алуны, аны чистартуны, транспортировкалауны һәм халыкка су бирүне тәэмин итә торган башка инженерлык корылмаларын проектлау, төзү һәм ремонтлау;

3.Әлеге карарны Яңа Арыш авыл җирлегенең түбәндәге адресы буенча урнашкан махсус мәгълүмат стендларында урнаштырырга: Татарстан Республикасы, Балык Бистәсе муниципаль районы, Яңа Арыш авылы,Мәктәп урамы, 30 йорт; һәм Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтта: http:// ribnaya-sloboda.tatarstan.ru һәм Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге "Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматның рәсми порталында" түбәндәге веб-адрес буенча:

http://pravo.tatarstan.ru. 4.Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары Регистрына кертү өчен җибәрергә.

Гражданнар җыенында рәислек итүче Х.С.Зарипов

Яңа Арыш авыл җирлеге башлыгы Х.С.Зарипов